**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

# КАРАР

IV чакырылыш

06 октябрь 2022 ел № 32 Урыссу ш.т.п.

Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карарларын гамәлдән чыгару турында

Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Җир кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 № 248-ФЗ Федераль закон, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда, юридик затларның һәм хосусый эшмәкәрләрнең хокукларын яклау" 26.12.2008 ел, № 294-ФЗ Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Тикшерү кәгазьләре формалары проектларын эшләүгә, эчтәлегенә, җәмәгатьчелек фикер алышуына, тикшерү кәгазьләре формаларын раслауга, куллануга, актуальләштерүгә, шулай ук тикшерү кәгазьләрен мәҗбүри куллану очракларына таләпләрне раслау турында» 27.10.2021 ел, № 1844 Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Советының 28.04.2020 № 18 карары белән кабул ителгән "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы норматив хокукый актларын гамәлдәге законнарга туры китерү белән бәйле, Татарстан Республикасы Ютазы районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы район Советының түбәндәге карарларын гамәлдән чыгарырга:

- «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру барышында кулланыла торган тикшерү кәгазенең (контроль сораулар исемлегенең) формасын раслау турында» 2022 елның 28 гыйнварындагы 5 номерлы карарын;

- “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру барышында кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасын раслау турында” 2022 елның 28 гыйнварындагы 7 номерлы карарын;

- «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру барышында кулланыла

торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасын раслау турында» 2022 елның 28 гыйнварындагы 9 номерлы карарын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасының
Ютазы муниципаль районы Башлыгы -
Татарстан Республикасының
Ютазы район Советы Рәисе А. Ә. Шәфигуллин